**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Какре-Елгинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Советская, д. 22 , село Какре-Елга
Азнакаевского муниципального района,
423320
Тел. (факс) (85592)37-0-49
KelgAzn@tatar.ru

Совет урамы, 22, Кәкре Елга авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233230
Тел. (факс) (85592) 37-0-49
KelgAzn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» март 2022 ел № 1

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының 2022 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында»

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Кәкре Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга Советының 2012 елның 19 апрелендәге 37 номерлы карары белән кабул ителгән авыл җирлеге халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын гамәлгә ашыру максатыннан Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының «2022 елда Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында» гы карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен халык алдында тыңлаулар үткәрү максатыннын карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең 2023 елгы бюджеты үтәлеше турында"гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы - Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2023 елның 10 апреле 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны-Кәкре Елга авылы мәдәният йорты.
- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим ителә торган адрес: 423320 ТР, Азнакай районы, Кәкре Елга авылы, Совет урамы, 23 а.

4. Азнакай муниципаль районы Кәкер Елга авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының "2023 елда Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проекты буенча, гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең норматив-хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокта ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының "2023 елда Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проектын (1 нче кушымта) Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) веб-адресы буенча 2023 елның 16 мартыннын да сонга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru ,Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http//aznakayevo.tatar.ru//. 2023 елның 16 мартыннан да соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Кәкре Елга авыл
җирлеге башлыгы
Азнакай муниципаль районы башлыгы — И.М.Мөхәмәтҗанов